РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Большекармалинского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Олы Карамалы**
**авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул.Центральная, 4,с.Большие Кармалы, 422830
тел. (8277)35-2-38, факс: (8277) 35-2-38
ОКПО 93065191, ОГРН 1061672018022
ИНН/КПП 1622004612/162201001

Узэк урамы , 4,Олы Карамалы авылы, 422830,
тел. (8277)35-2-38, факс: (8277) 35-2-38
ОКПО 93065191, ОГРН 1061672018022
ИНН/КПП 1622004612/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**“17” сентябрь 2018 ел** **№10**

**Җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында”гы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы “Җирле референдум турында”гы Татарстан Республикасы Законының 17 маддәсе, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Уставының 15 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР КЫЛА:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге территориясендә түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

"Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге территориясендә турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән, (биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларыннан кала) җирлек территориясендә тавыш бирү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2019 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме:

*** Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**
*** Күмү урыннарын карап тоту;**

*** Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру:**
*** Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм ташу эшчәнлеген оештыру.**

ӘЙЕ ЮК”

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:
-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Олы Карамал авылы, Үзәк урам, 4 йорт,
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәрлегуҗа авылы, Тукай урамы, 16 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Олы Карамалы авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Э. И. Бәйдамшин